ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.02.2026 г. Заинск № 68

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 30 июлендәге 353 номерлы «Хөкем ителгәннәр өчен төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны узу урыннарын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Җинаять кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 299 статьясындагы беренче өлешенең 7.1 пунктының үз көчен югалтуын тану турында» 2025 елның 23 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 30 июлендәге 353 номерлы «Хөкем ителгәннәр өчен төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны узу урыннарын билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “төзәтү һәм" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1.1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. «Төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгән затлар җәзасын үтәү өчен төп предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр исемлеге (килешү буенча)» 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

юрист

О.Р. Харитонова
9 90 57